СОВЕТ НИЖНЕОШМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.37 А, с. Нижняя Ошма, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422164

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТУБӘН УШМЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Советлар урамы, 37А йорт, Түбән Ушмы авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы, 422164

тел.(факс): (85563) 2-34-46; e-mail: Noshm.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение Карар
20 ноябрь 2018 ел №2-36

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлегенең 2017 елның 25 августындагы «Мамадыш муниципаль районының Түбән Ушмы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленең бер кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт алу тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2-22 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлегенең 2017 елның 25 августындагы «Мамадыш муниципаль районының Түбән Ушмы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленең бер кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт алу тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2-22 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Мамадыш муниципаль районының Түбән Ушмы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленең бер кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт алу тәртибе турындагы нигезләмәнең 1 Пунктына түбәндәге сүзләрне өстәргә:

« әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә, муниципаль берәмлек исеменнән муниципаль милектә булган акцияләрне (устав капиталында катнашу өлешләре) гамәлгә куючы яисә аның белән идарә итү вәкаләтләрен (устав капиталында

катнашу өлеше) гамәлгә куючы (акционер), муниципаль берәмлек булган оешманың идарә итү органнарында һәм Ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итүдән тыш, муниципаль берәмлек исеменнән гамәлгә куючы яисә муниципаль хокукый актлар нигезендә; федераль законнарда каралган башка очракларда.»

2. Әлеге карар «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында (pravo.tatarstan.ru) рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы  авыл җирлеге башлыгы Р.М.Ганиевка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Түбән Ушмы  авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе М.Ганиев/